# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлегендә Нормабаш авылында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

25 ноябрь, 2024 ел №3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Нормабаш авылы гражданнар җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:
2025 елда Татарстан Республикасы Кукмара районы Байлангар авыл җирлегенең Нормабаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән: 1 төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар),18 яшькә кадәрге баласын тәрбияләүче ялгыз аналар, 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк баласы булган аналар, 80 яшькә җиткәннәр һәм аннан да өлкәнрәкләр, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары, махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала» 2000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- **торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (юлларга вак таш һәм асфальт салу, карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре); (Нормабаш авылында урам-юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, юлларны карап тоту буенча башка эш төрләре);
- **торак пункт территориясен төзекләндерү** (Һ. Такташ урамындагы газүткәргечне демонтажлау, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, шартнамә буенча түләү, газүткәргечне төзү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре; (Нормабаш торак пунктында агачларны кисү, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, җирлек территориясен төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- **традицион күмү урыннарын төзекләндерү, коймалар кору, ремонтлау**(Нормабаш авылы зираты территориясен карап тоту һәм төзекләндерү, инвентарь сатып алу, проект-смета документларын эшләү, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);

- **су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау** (су белән тәэмин итү

челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре)

**- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау**(урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре); (урам электр челтәренең 5 нче линиясен төзү, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, урам электр челтәрен төзү, карап тоту буенча башка эш төрләре);

**- Нормабаш авылындагы «Ял итү зонасы, балалар уен мәйданчыгы, Нормабаш авылында Бөек Ватан сугышы обелискы»н ремонтлау һәм аның янындагы территорияне төзекләндерү** (яздырып, гранит мемориаль такта сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, «Ял итү зонасы, балалар уен мәйданчыгы, Нормабаш авылында Бөек Ватан сугышы обелискы»н төзекләндерү буенча башка эш төрләре)

- **Нормабаш авылында** автомобиль күперен рәтләү һәм ремонтлау (проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, автомобиль күперен карап тоту буенча башка эш төрләре)

3. Әлеге карарны Байлангар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына http://pravo.tatarstan һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында kukmor.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Байлангар авыл җирлеге
башлыгы: И.Ф.Каримуллин